СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                                 Карар

№ 3-30                                                                 15 декабрь 2023 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 июлендәге1-11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 июлендәге1-11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:"12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;".
2. Әлеге карарны җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru)

урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Урта Кирмән
авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасанов